# КАРАР

**22 ноябрь, 2023 ел** **№ 1**

**Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлеге Нормабаш авылында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2023 елның 22 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде: «Сез 2024 елда Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Байлангар авыл җирлеге Нормабаш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, түбәндәгеләрдән тыш:

- 1 төркем инвалидлары;
- көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлар (курсантлар);
- 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналар;
- 18 яшькә кадәрге 3 һәм аннан да күбрәк баласы булган аналар;
- 80 яшькә җиткәннәр һәм аннан да өлкәнрәкләр;
- Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлар;
- Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзалары»

1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Нормабаш авылының Вахитов урамы юлына вак таш җәю (проект-смета документларын эшләү, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, вак таш сатып алу, ташу, салу, килешү буенча эш өчен түләү)

- Нормабаш авылының Вахитов урамында 5 нче урам яктырту линиясен үткәрү (материал сатып алу, проект-смета документларын эшләү, килешү буенча түләү)

- Һ. Такташ урамындагы газүткәргечне демонтажлау (проект-смета документларын эшләү , килешү буенча түләү)

- Нормабаш авылы зиратлары территориясен карап тоту һәм төзекләндерү (инструментлар һәм инвентарь сатып алу, проект-смета документларын эшләү, килешү буенча түләү)

- Сүүткәргеч челтәрләрен һәм су суырту манараларын ремонтлау, карап тоту, төзекләндерү (артезиан скважиналары өчен насослар сатып алу, материаллар сатып алу, проект-смета документларын эшләү, материал сатып алу, килешү буенча түләү)

- Урам яктыртуны карап тоту (энергия саклаучы лампалар, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, килешү буенча түләү)

- Нормабаш авылындагы юлларны кышкы-җәйге чорда карап тоту (ягулык-майлау материаллары һәм запас частьләр сатып алу, килешү буенча эш өчен түләү)

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 72 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны – 37 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 37 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы **0** кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлегенең Нормабаш авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны:«Сез 2024 елда Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Байлангар авыл җирлеге Нормабаш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, түбәндәгеләрдән тыш:

- 1 төркем инвалидлары;
- көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлар (курсантлар);
- 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналар;
- 18 яшькә кадәрге 3 һәм аннан да күбрәк баласы булган аналар;
- 80 яшькә җиткәннәр һәм аннан да өлкәнрәкләр;
- Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлар;
- Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзалары»

2100 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- юлларга вак таш һәм асфальт салу, карап тоту, ремонтлау һәм төзекләндерү, проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, юлларны төзү, карап тоту һәм төзекләндерү буенча башка эш төрләре;

- урам электр челтәренең 5 нче линиясен төзү, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, урам электр челтәрен төзү, тоту буенча башка эш төрләре;

- Һ. Такташ урамындагы газүткәргечне демонтажлау, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, газүткәргечне төзү, тоту буенча башка эш төрләре;

- Нормабаш авылы зираты территориясен карап тоту һәм төзекләндерү, инвентарь өчен будка төзү, бәдрәф төзү, инвентарь сатып алу, проект-смета документларын эшләү, зират территориясен төзекләндерү һәм карап тоту буенча башка эш төрләре;

- су белән тәэмин итү челтәрләрен, су саклау зоналары һәм су суырту манараларын карап тоту, ремонтлау һәм төзекләндерү, артезиан скважиналары өчен насослар сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, су белән тәэмин итүне, су саклау зоналары һәм су суырту манараларын карап тоту буенча башка эш төрләре;

- урам яктыртуны карап тоту, комплектлау материаллары сатып алу һәм урнаштыру, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү, урам яктыртуны карап тоту буенча башка эш төрләре;

- Нормабаш авылында урам-юл челтәрен карап тоту, ягулык-майлау материаллары һәм запас частьләр сатып алу, проект-смета документлары, юлларны карап тоту буенча башка эш төрләре;

- Нормабаш торак пунктында агачларны кисү, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, торак пункт территориясен төзекләндерү буенча башка эш төрләре;
- Нормабаш авылы зиратында агачларны кисү, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, зиратны төзекләндерү буенча башка эш төрләре;

«РИЗА» «КАРШЫ»

кабул ителгән дип исәпләргә.

3. Гражданнар җыенның нәтиҗәсен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ruадресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Байлангар авыл җирлеге башлыгы: И.Ф. Кәримуллин